Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САБА ШӘҺӘР ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“02” декабрь 2019 ел № 44

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2019нчы елның 2нче декабрендә кабул ителгән 93/1 номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге биләмәсендә 2019 елның 1 декабрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында”гы карарын теркәү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2019нчы елның 2нче декабрендә кабул ителгән 93/1 номерлы “2019 елның 1 декабрендә “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге биләмәсендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында” мөрәҗәгатен караганнан соң, Татарстан Республикасының 24.03.2004 елгы 23-ЗРТ номерлы “Җирле референдум турында” Законының 60 нчы статьясы, 3 нче пунктына, Саба шәһәр җирлеге Советының 2014нче елның 13нче маенда кабул ителгән 19 нчы номерлы “Саба шәһәр җирлеге биләмәсендә гражданнарның үзара салым акчасы, аны җыю һәм куллану турында Нигезләмәне раслау турында” карарына, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына, Саба шәһәр җирлеге Советының 2016нчы елның 23нче декабрендә кабул ителгән 51 нче номерлы “Саба шәһәр җирлеге биләмәсендә гражданнарның үзара салым акчасы, аны җыю һәм куллану турында Нигезләмәне раслау турында карарына үзгәрешләр кертү турында” карарына таянып, 2019нчы елның 1нче декабрендә булып узган референдумда гаржданнарның “Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең һәм Урта Саба авылының урам юлларын төзекләндерү һәм вак таш белән түшәү;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә һәм Урта Саба авылында чишмәләр һәм зиратларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең тышкы яктыртылышын монтажлау;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә су белән тәэмин итү челтәре төзелешен проектлаштыру;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә агачлар һәм куаклар утырту? ӘЙЕ/ЮК" соравына бирелгән тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2019нчы елның 2нче декабрендә кабул ителгән 93/1 номерлы "2019 елның 1 декабрендә үткәрелгән "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге биләмәсендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында" карарын кушымта нигезендә рәсми рәвештә теркәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба шәһәр җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырырга.

3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Саба шәһәр җирлеге
башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов